**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хәрби комиссариатында хәрби-табиб комиссиясе эшен оештыру турында**

Россия Федерациясе Президентының «Хәрби комиссариатлар турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 07 декабрендәге 1609 номерлы Указы, 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, контракт буенча хәрби хезмәткә барырга теләк белдергән гражданнарга карата хәрби-табиб экспертизасы мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү максатында, белем бирү оешмаларын тәмамлаган хәрби үзәкләрдә хәрби әзерлек узучы һәм узарга теләк белдерүчеләр, белем бирү оешмаларын тәмамлаган, белем бирү оешмалары каршындагы хәрби кафедраларда (хәрби уку факультетларында) хәрби әзерлек узган, узарга теләк белдерүчеләр, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең мобилизацион гражданнар, хәрби җыеннарга чакырганда һәм запастагы хәрбиләрне исәпкә алу максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Запастагы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган гражданнарның яраклылыгы турында, хәрби җыеннарга чакырылучылар, Россия Федерациясе Кораллы көчләре запасында булган, училищеларга һәм хәрби-уку йортларына керүче гражданнар, хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмә нигезендә бәяләмә чыгару хокукы белән хәрби-табиб комиссиясен төзергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы хәрби-табиб комиссиясенең төп һәм резерв составын Актаныш районы хәрби комиссарының 2021 елның 25 декабрендәге 85 номерлы карары нигезендә расларга.

3. Запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган Актаныш муниципаль районы гражданнарын медицина тикшерүе уздыру өчен Актаныш районы үзәк хастаханәсен (килешү буенча) җәлеп итәргә.

4. Гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру чорында «2022 елда, 1995-2004 елларда туган гражданнарны хәрби хезмәткә чакырганда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы чакыру комиссиясенең эш планы» белән расланган составта күрсәтелгән гражданнарга медицина тикшерүен уздыру өчен кирәкле табиб-белгечләр бүлеп бирергә.

5. Актаныш районы үзәк хастаханәсенең баш табибына тәкъдим итәргә:

-«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»1998 елның 53-ФЗ номерлы РФ законы нигезендә табиб-белгечләр һәм урта медицина персоналын бүлеп бирергә.

- медицина тикшерүе уздыру чорында медицина комиссиясе эшендә катнашучыларны төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклап калу белән төп эштән азат итәргә;

- табиб-белгечләр булмаганда, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы белән аларны башка медицина учреждениеләреннән бүлеп бирүне килештерергә;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, медицина комиссиясен кирәкле медик-санитар мөлкәт белән тәэмин итәргә;

- медицина тикшерүе үткән чорда югарыда күрсәтелгән гражданнарга кулларына нәтиҗәләрен биреп, тиешле тикшеренүләр оештырырга һәм үткәрергә;

- Актаныш район үзәк хастаханәсендә стационар тикшерү өчен 2 койка-урын бүлеп бирү, бу максат өчен иң җаваплы табиб-белгечләрне беркетү һәм тулы һәм сыйфатлы тикшерүне тәэмин итәргә;

- дәвалау-профилактика учреждениеләре гаебе белән гражданнарны тикшерүне нигезсез сузу очраклары турында кичекмәстән хәбәр итәргә һәм аны тәмамлау өчен конкрет чаралар күрергә.

6. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керүче гражданнарга медицина тикшерүләрен үткәрү өчен штаттан тыш даими хәрби-табиблык комиссиясен төзү турында» 2020 елның 09 декабрендәге ПР-276 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны килешү буенча Актаныш районы хәрби комиссарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.Ф.Нурлыева